**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КОШТАУЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

2024 ел, 14 август №160

**Коштаулы авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Коштаулы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге Советының «Коштаулы авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 9 мартындагы 63 номерлы карары белән расланган Коштаулы авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле 18.17 пункт өстәргә:

«18.17.Физик һәм юридик затлар, муниципаль берәмлек территориясендә таралуны булдырмау максатларында, Сосновский борщевигының милек хокукында яисә башка хокукларда үзләренә караган җир кишәрлекләрендә (шул исәптән коймалар һәм биналар һәм корылмалар фасадлары буйлап) һәм аларга якын территорияләрдә үсүенә юл куймаска тиеш.».

2) түбәндәге эчтәлекле 40.10 пункт өстәргә:

«40.10. Үләнне һәм чүп үләннәрен чаптырырга, агачларның коелган яфракларын җыярга, Сосновский борщевигын, кыргый киндер (кыргый чүп каннабисы) һәм мак самосейканы (кыргый, кыр) юк итәргә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (apastovo.tatarstan.ru).

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирлек башлыгына йөкләргә.

**Коштаулы авыл җирлеге башлыгы,**
**Коштаулы авыл җирлеге Советы Рәисе Х.Ф.Сабиров**